32. Gasryi, N. (1914). *Odin ehpizod iz zhizni molodezhi* [One Episode from the Life of the Youth]. Il (Strana). 2 yanvar' (No. 10). (In Russian)

33. Validi, Deh. (1914). *Odin ehpizod iz zhizni molodezhi* [One Episode from the Life of the Youth]. Vakyt (Vremya). 26 yanvar'. (In Russian)

34. Gilazov, T. Sh. (2017). *Rasskaz G. Ibragimova "Odin ehpizod iz zhizni molodezhi" v literaturnoi kritike 1910–kh godov* [G. Ibragimov's Story "One Episode from the Life of the Youth" in Literary Criticism of the 1910s]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 2(48), pp. 153–158. (In Russian)

35. Gosmanov, M. (2000). *Primer roskoshi* [An Example of Luxury]. Fatikh Karimi: Nauchno-biograficheskii ocherk. Fatikh Karimi: Nauchno-biograficheskii sbornik. 320 p. Kazan', Rukhiyat. (In Russian)

36. Kerimi, F. (1912). *Ahmet Mithat Efendi ve Şimal Türkleri* [Ahmet Mithat Efendi and the Northern Turks]. Türk Yurdu, sayı 30, sh. 97. (In Turkish)

37. Bargan, Kh., Gilazov, T. Sh. (2014). *Akhmed Midkhat afandi i ural'skie tyurki* [Akhmed Midkhat Efendi and the Ural Turks]. TATARICA. No. 1(2), pp. 70–80. (In Russian)

# Г.ИБРАҺИМОВНЫҢ «БЕЗНЕҢ КӨННӘР» (1920) РОМАНЫ ӘДӘБИ ҺӘМ МӘДӘНИ БӘЙЛӘНЕШЛӘР ЯКТЫЛЫГЫНДА

**Таһир Шәмсегали улы Гыйлаҗев,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
tgilazov@bk.ru.

Мәкаләдә күренекле татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» (1920) романы өйрәнелә. Бу әсәрендә әдип Беренче рус революциясе һәм реакция елларында татар җәмгыятенең төрле катламнарын сурәтли. Роман үз чорының көнүзәгендәге социаль, иҗтимагый, милли һәм мәгърифәтчелек проблемаларының куелышы ягыннан язучының беренче дәвер иҗатында аерылып тора. Яктыртылган мәсьәләләрнең бер шәлкеме татар әдәбияты классиклары Г. Исхакый, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, Г. Камал, Н. Думави иҗатлары белән яңгыраш булса, татар тормышын яңарту һәм мәдәниләштерү турындагы иҗтимагый фикерләре исә Җ. Вәлиди, Н. Гасрый, И. Гаспралы, М. Бигиев һ.б.ларның карашларына барып тоташа. Шул вакытта Г. Ибраһимовның бу әсәрендә гарәп-мөселман, төрек һәм гареб мәдәнияте, фәлсәфәсе, Коръән тәгълиматы белән бәйләнешләр дә көчле бирелә. Мәкаләнең өйрәнү объекты булган «Безнең көннәр» романын XX гасыр башы әдәби, тәнкыйди, иҗтимагый, этик-әхлакый, эстетик һәм фәлсәфи фикере белән бәйләнешләр ноктасыннан тикшерү аның максаты булып тора. Әдәби әсәрнең басылып чыгу, тикшерелү тарихына кыскача күзәтү ясала.

**Төп төшенчәләр:** Галимҗан Ибраһимов, роман, әдәби бәйләнешләр, иҗтимагый фикер, мәдәният

## Кереш

Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романы Беренче рус инкыйлабы елларында хәрәкәткә килгән төрле катлау, төркем, зыялы яшьләрнең милли сәясәт юлында эзләнүләрен, татар җәмгыятен яңарту һәм үстерү юллары хакындагы иҗтимагый-фәлсәфи уйлануларын тасвирлаган киң колачлы әсәр булып тора. Мәгълүм булганча, бу әсәрнең ике варианты бар. Г. Ибраһимов романның беренче вариантын аерым мәгълүматларга караганда, 1914 елда язып тәгәлли. 1914 елның 25 апрелендә Сухумидән Х. Кәримгә юллаган хатында ул түбәндәге мәгълүматны бирә: «Сиңа язмадым бугай, мин бит „Безнең көннәр“ язам. Бу „Хәят дулкыннары“ атлы трилогиянең беренче җөзье (бүлеге. – *Т. Г.*) була. Хәзерге чамаларда өч йөздән артмас кебек. Ахырга таба арта торган булса, ничек булыр. Моны Гәрәйләргә бирәм. Килештек. Мин май ахырларына матбагага бирергә булыр дигән нияттәмен» [1, 82 б.]. Димәк, Ибраһимов романны 1914 ел җәендә тәмамлап, «Гасыр» нәшриятына басарган биргән. Аның сиксән бите җыелып, ике табагы басылса да, әсәрдә патша самодержавиесен тәнкыйтьләүгә һәм инкыйлаби хәрәкәткә зур урын бирелү аркасында, цензура тарафыннан нәшер итү туктатыла. «Безнең көннәр» романы үзгәртелмичә, 1920 елда гына басылып чыга.

1920 елларның икенче яртысында, татар әдәбият чынаклары белеме һәм текстология фәне тернәкләнә башлау нәтиҗәсендә, аерым әдипләр әсәрләренең фәнни басмаларын чыгару көн тәртибенә куела: Г. Ибраһимовның җиде томлыгын нәшер итү ният ителә. Шушы уңайдан язучы «Безнең көннәр»нең беренче вариантын «әдәби балачак» чоры әсәре дип бәяләп, яңадан үзгәртеп эшли. «Сайланма әсәрләрнең өченче-дүртенче китабы булып барган „Безнең көннәр“ романы бу икенче басма өчен автор тарафыннан карап чыгылды һәм яңа редакция астына алынды. Ачыграк әйткәндә, әсәр егерме елдан соң тагы бер кат, бөтенләй диярлек, яңадан эшләнде» [2, 435 б.]. Әдип романның композициясен һәм художество эшләнешен камилләштерә. Яңа архив материалларын һәм документларны файдалана, социал-демократик партиядән кала барлык сәяси агымнарга, милли хәрәкәт вәкилләренә, буржуазиягә тискәре мөнәсәбәтне көчәйтә, ягъни Беренче рус революциясе чоры вакыйгалары һәм реакция күренешләре пролетариат идеологиясе, сыйнфыйлык ноктасыннан яктыртыла. Яңадан эшләнгән роман 1934 елда басылып чыга [3]. Әдипнең иң тулы фәнни басмасы саналган тугыз

томлыкның дүртенче томына урнаштырылган «Безнең көннәр» романы 1976 елда аерым кыскартулар белән дөнья күрә [4]. Бу урында шул фактны искәртү урынлы булыр: романның икенче варианты басылып чыккач, 1920 елдагы нәшер онытылуга дучар ителә.

XXI гасырның унынчы елларында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан Г. Ибраһимов әсәрләренең академик басмасын әзерләү проблемасы көн тәртибенә куелгач, фәнни редколлегия 1920 елда «Сабах» нәшриятының «Өмид» типографиясендә басылган «Безнең көннәр» романын мөстәкыйль том итеп бастырып чыгару фикеренә килә. Язучының киңкырлы мирасын иңләгән 15 томлыкның 4 томында ул, кириллицага күчерелеп, тулы килеш дөнья күрде [5].

Күренә ки, Г. Ибраһимов тарафыннан иҗат ителгән «Безнең көннәр» романының беренче варианты нәшер ителү тарихына да замананың иҗтимагый һәм сәяси җилләре тәэсир итә. «Безнең көннәр» (1920) романының беренче варианты басылып чыгу белән, әдәби җәмәгатьчелекнең, гыйльми-тәнкыйди фикернең игътибарын үзенә җәлеп итә. Төрле шәкелдәге тәнкыйди язмаларда әсәрнең темасы, язучының осталыгы, сурәтләнгән типларның һәм күренешләрнең тормышчанлыгы [6, 364 б.], [7, 366 б.], «татар иске режимының һәм 1905 елгы Беренче революция картинасының бик яхшы сурәтләнеше» [8, 368 б.] билгеләнә. Бәяләрдә яңа социаль-иҗтимагый һәм икътисади шартларда беренче адымнарын ясый башлаган марксистик-ленинчыл методологиянең сәяси кагыйдәләренең, үлчәмнәренең тәэсире дә үзен сиздерә. Мәсәлән, Ф. Сәйфи-Казанлы «Кызыл шәрык» журналында басылган «Галимҗан Ибраһимовның соңгы әдәби әсәрләреннән „Безнең көннәр“ романы» рецензиясендә татар революционерлары эшчәнлеген, тарихи вакыйгаларны бәйнәлмиләл яссылыкта, ягъни Франция, Алмания, Швецария дәүләтләренең пролетариатлары хәрәкәте кысаларында бәяли. Халыкчы Хәбиб Мансуров хакында ул болай дип яза: «Сәрүҗи (Хәбиб Мансур. – *Ф. С.*) – суык канлы, һич арымас, революция өчен тауташ җимереп чыгып, идеясенә хезмәт итә торган революционер. Бу ниндидер гареб мәдәнияте белән сугарылып, Париж баррикадаларында туган француз пролетариатын, инглиз үзсүзлеген, немец чыдамлыгын искә төшерә. Шуның өчен боның һәр милләт психологиясенә, тарихына таныш бер тип икәне күренәдер» [6, 366 б.]. Рус галиме, шәркыят белгече П. Фалевның «Татарский революционный роман» мәкаләсе «Безнең көннәр»гә эстетик анализы белән мөмтаз урында тора. Язма авторы инкыйлаби хәрәкәтне һәм каһарманнарны татар иҗтимагый-милли җирлегендә бәяли, аның хосусиятләрен аерып чыгара. Социал-демократ Зариф Булатов идеяләренең киң таралыш алмавы П. Фалеев тарафыннан «татарларда пролетариат сыйныфының булмавы, 1905 елгы революциянең мөселманнар арасында бары тик зыялылар хәрәкәтендә чагылышына» нисбәтле аңлатыла (сүзгә-сүз тәрҗ. – *Т. Г.*) [9, 375 б]. Г. Сәгъдинең 1926 елда нәшер ителгән «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтендә Г. Ибраһимов иҗаты яктыртылган бүлекчәдә романның басылу тарихы, темасы, образлар системасы тикшерелә. 1920 елларның беренче яртысында басылып чыккан язмаларга күзәтү ясалып, алардан романның төп хасиятләрен ачарга булышкан өзекләр китерелә [10, 142–147 б.]. Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Г. Нигъмәтинең күләмле мәкаләсендә «Безнең көннәр» романының беренче вариантына идея-эстетик бәя бирелеп, аның тематикасы һәм проблематикасы, геройлар системасы, сәнгати үзенчәлекләре төрле яклап – типларның һәм вакыйгаларның реаль җирлеге, тасвирый алымнарның язучы әсәрләре белән эчке бәйләнеше һәм башка нокталардан тикшерелә [11, 92–118 б.].

XX гасыр ахырында – XXI гасыр башында Г. Ибраһимовның тулы мирасын өйрәнү һәм кайтару мәсьәләсе куела һәм шушы уңайдан «Безнең көннәр» романының беренче – 1920 елда басылып чыккан вариантына яңадан игътибар ителә башлый. Әүвәл әдәби җәмәгатьчелекнең игътибары язучының марксистик-ленинчыл идеология басымы астында «оныттырылган» әсәрләренә юнәлә. М. Ш. Җәләлиеваның әдипнең тууына 115 тулу уңаеннан язылган «„Безнең көннәр“ романының ике варианты» дигән язмасы игътибарга лаек. Галимә әсәрнең ике вариантына чагыштырма анализ ясый. Романның беренче вариантын иҗтимагый-милли җирлектә тикшереп, вакыйгаларның шактый киңлеген, хәрәкәтнең куелыгын, дулкынлы көрәшнең куәтле булуын, персонажларның катлаулы язмышлары сурәтләнүен «Безнең көннәр»нең асыл

хосусиятләре төсендә билгели [12, 75 б.]. Романга тулы, комплекслы анализ дәгъва итмичә, аның аерым темалары өйрәнелгән язмаларда «татар милләтенең яшәү-яшәмәү кебек иң әһәмиятле, көнүзәк мәсьәләсенә әверелгән» уку-укыту проблемалары һәм аларга язучының мөнәсәбәте шәрехләнә [13, 129 б.]. Әдип әсәрләренең текстологиясе мәсьәләсе тирәсендә күзәтүләре белән уртаклашкан язмада текстолог һәм әдәбиятчы галим З. Рәмиев болай дип әйтә: «Җәмәгатьчелектә „Безнең көннәр“ романының 1919[1] елда Казанда нәшер ителгән беренче вариантын да ныклап өйрәнергә, басмаларына кертергә кирәк дигән фикер күптәннән йөри. Бик дөрес фикер бу, чөнки 30 еллар башында Ялтада Г. Ибраһимов аның яңабаштан язылган вариантын барлыкка китерә һәм ул 1934 елда басылып чыга» [14, 83 б.].

«Безнең көннәр» романы 1905 елгы инкыйлаби вакыйгаларны яктыртуны максат итсә дә, Г. Ибраһимов шушы тарихи вакыйгаларда катнашкан татар халкының төрле катламнары хәрәкәтен, милли тормышның киң понарамасын яктыртуга ирешә һәм үз чорының мөһим проблемаларын күтәрә. Ул гына да түгел, аерым геройларның фикри-мәгънәви үзгәреше фонында иске татар тормышын мәдәниләштерү һәм яңарту юлларын да күрсәтә. Фәнни мәкаләдә «Безнең көннәр» романының беренче вариантын XX гасыр башы әдәби, гыйльми-тәнкыйди, иҗтимагый, фәлсәфи фикере белән бәйләнешләр яктылыгында тикшерү омтылышы ясала. Хезмәт темасының фәнни яңалыгы шуның белән билгеләнә.

### Фәнни хезмәтнең материалы һәм методлары

Мәкаләдә Г. Ибраһимовның 1914 елда тәмамланып та, 1920 елда «Сабах» нәшриятының «Өмид» матбагасында басылып чыккан киң масштаблы «Безнең көннәр» тарихи-инкыйлаби романы чыганак булып тора [5]. Аерым фактларны ачыклау һәм төгәлләштерү максаты белән, язучы әсәрләренең академик нәшеренең бишенче томына [15] һәм 1974–1987 елларда дөнья күргән сигез томлыгының дүртенчесенә урнаштырылган «Безнең көннәр»гә дә мөрәҗәгать ителде [4].

Тикшерү методлары һәм принциплары гыйльми эзләнү хезмәтенең максатына һәм өйрәнү объектына нигезләнеп сайланылды. Әдәби иҗатны, әсәрне шәрехләү һәм анализлауның культура-тарих, чагыштырма-тарихи, типологик, биографик, герменевтика методлары, тарихилык һәм миллилек принциплары файдаланылды. Культура-тарих методының «раса-тирәлек-момент» чылбырындагы һәр буын Г. Ибраһимов романын тарихи һәм милли закончалыклар, милли психология, XX гасыр башында татар хакының традицияләре һәм мәдәнияте, яңарыш чоры хосусиятләре белән тыгыз бәйләнештә өйрәнүгә методологик юнәлеш бирде.

### Фикер алышу

Тарихи роман жанрында иҗат ителгән «Безнең көннәр» (1920) әсәренең идея эчтәлеге, бер яктан, XX гасыр башындагы иҗтимагый фикер, икенче яктан, шул чорның әдәби хәрәкәте белән тыгыз бәйләнгән. Роман үз чоры милли хәятының көнүзәгендәге мәсьәләләрен яктырта, аның аерым кисәкләрендә татар җәмгыятен яңарту, мәдәниләштерүнең юллары тәкъдим ителә. Әсәрдә гәүдәләнеш тапкан мөһим проблемалар Җ. Вәлиди, Н. Гасрый, М. Бигиев, И. Гаспралы кебек күренекле галимнәрнең, фикер ияләренең, мәгърифәтчеләрнең карашлары, икенче яктан, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, М. Гафури, Н. Думави һәм язучының үз әдәби әсәрләрендәге бәя-хөкемнәр белән авaздаш.

Романда төрле сәяси партияләр, аеруча татар эсерлары һәм социал-демократлары монархиягә, буржуазиягә каршы бердәм көрәш алып бара. Г. Ибраһимов иске татар тормышын үзгәртеп коруга нисбәтле, зыялы яшьләр арасындагы идеологик бәхәс, сәясәткә киң урын бирсә дә, инкыйлаб елларында уртак идеал хакына барлык сәяси агым вәкилләренең берләшеп, кулга-кул тотынышып хәрәкәт итүләренә басым ясый [16, 47 б.]. Хәрәкәт бердәмлеге төрле партия һәм партиясезләрне бергә җыйган «Мәдрәсәи Исламия»нең шәкерт җыелышларыннан берсендә Җиһангир тарафыннан сөйләнгән нотыкта ассызыклана: «... Бездә җан булса, бездә аң булса, татар милләтенең караңгы киләчәген яктыртырга хезмәт кылу дәрте булса, бездә үземезне адәм дип белерлек, үземезне издермәслек <...> мыскыл иттермәслек намус вә куәт булса, без иптәшләр, берләшергә, бер-беребезгә кул бирешергә тиешле. Менә бу җәмгыять шул

[1] Китапның басылып чыгу датасы титул битендә 1919 ел дип күрсәтелә, әмма ул чынлыкта 1920 елның урталарында гына дөнья күрә. Фәнни хезмәтләрдәге төрлелек шуның белән аңлатыла.

турыда булачак. ... Мәсьәлә мөһим, иптәшләр, берләшик, көрәшик, көрәшүдә табарсың син үз хакыңны» [5, 84 б.]. Төрле идея юнәлешендә торган катламнарны берләштерерлек көчләр дә табыла. «Демократлар эчендә Булат, революционерлар эчендә Урманов кебек ике яктан бертигез диярлек мәхәббәт казанган иптәшләр булуы да бу ике партия кешеләренең береннән гамәлдә күп ераклашмавына сәбәп була иде» [5, 250 б.] – дип яза Г. Ибраһимов. Татар буржуазиясе хәрәкәте белән пролетариат хәрәкәте арасында ислахчылар-шәкертләр зур роль уйный. Әдәби әсәрдә «Мәдрәсәи Исламия» шәкертләре хәрәкәтен сурәтләүгә зур урын бирелә, ул әсәрнең өчтән бер өлешен алып тора. Шәһәрне иңләп алган шәкертләр кузгалышының сәбәпләре мәдрәсәләргә ислах, уку-укыту программаларын, ысулларын яңарту белән генә чикләнмичә, иҗтимагый һәм милли проблемалар белән дә тыгыз бәйләнгән.

«Безнең көннәр» романында XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы әдәби һәм иҗтимагый, фәлсәфи фикере белән бәйләнеш шәкертләрнең, мөселманнарның шәһәр җыелышларында яңгыраган төрле социаль катлам вәкилләренең, инкыйлабчыларның чыгышларында ачык чагыла. Шундый җыелышларның берсе шәһәрнең зур җәдиди мәдрәсәсе – «Мәдрәсәи Исламия»дә була. Г. Ибраһимов аны аерым чигенешләр белән бик җентекләп сурәтли. Ул әдәби әсәрнең 26 бүлеген тәшкил итә. Җыелыш мәдрәсәнең өченче катындагы зур залда бара. Төнге өчкә кадәр сузылган мәҗлестә татар тормышын яңарту, мәдәниләштерерү, татар милләтен үстерү мәсьәләсе төп көн тәртибе булып тора. Төрле сәяси фирка вәкилләре, шәкертләр, руханилар бу хакта үз карашлары һәм уйланулары белән уртаклаша. Нотыкчыларның күбесе, аеруча шәкертләр үз чыгышларын татар мәдрәсәләренең артталыгына, схоластик фәннәр укытылуга, идарәнең начар мөгаләмәсенә, яшәү шартларының начарлыгына тискәре мөнәсәбәт белдерүдән башлый.

Г. Ибраһимовның татар җәмгыятен үзгәртеп кору хакындагы уйланулары романның идеологик катламын барлыкка китерә. Анда, иң беренче, татар мәгърифәтчесе, педагог, журналист Исмәгыйль Гаспралы гыйбарәсенә аваздаш булган иҗтимагый-сәяси хәрәкәттә, бердәмлек, сүздә, фикердә бергә хәрәкәт итү фикере тәкрарлана һәм ул татар милләтен үстереп, бөеклеккә, муллыкка, бәхеткә ирештерүнең мөһим юлы төсендә тәкъдим ителә. «...Иттифак...(бер сүздә булу. – *Т. Г.*) Иттихад... (берләшү. – *Т. Г.*) Иттифак... Иттихад... Әфәнделәр һәр милләт болар аркасында тәрәккый вә тәгали итеп (бөек булып. – *Т. Г.*), әүеҗ сәгадәткә (бәхетнең иң югары ноктасына. – *Т. Г.*) ирешә» [5, 155 б.]. Бу идея революция дулкыны белән бер ташкын булып татар поэзиясенә килеп кергән Г. Тукайның «Иттифак хакында» (1905), М. Гафуриның «Инсаф вә иттифак» (1905), Н. Думавиның «Берлек-иттифак» (1906), «Рак, аккош, балык» (1906), «Умарта корты» (1906) шигырьләренә һәм мәсәлләренә барып тоташа.

Алга таба татар телендә газета-журналлар чыгару, тормыш күрнешләрен тасвирлап, укучының дөньяга күзен ачкан милли сүз сәнгатенең күтәрелеше, рус телен өйрәнү, рус һөнәри мәктәпләрендә, реаль училищеларында белем алу татар милләтенең европалашуына, мәдәниләшүенә хезмәт итә дигән фикер әйтелә. Чираттагы чыгыш ясаучы әдәбиятның милләтне үстерүенә мисал итеп реалист шагыйрь һәм прозаик М. Гафуриның «Себер тимер юлы, яки Әхвале милләт» (1904) поэмасын китерә: «Беренче милли шагыйрь мәшһүремез Мәҗит әфәнде Гафури хәзрәтләренең „Себер тимер юлы“ атлы шигыре минем күземне ачты, мине искелекнең хатасыннан якты юлга күндерде» [5, 158 б.]. Автор тарафыннан шушы чор нәзари фикерендәге «әдәбиятның милләткә файдалылыгы идеясе» ныгытыла.

Чыннан да, М. Гафуриның фән-техника казанышларына дан җырлаган бу әсәре бу елларда укучы яшьләр, татар шәкертләре арасында бик популяр була. 1908 елда А. П. Пинкевичның (Пенькевич) «Камско-Волжская речь» газетасында «Очерки новейшей татарской литературы» [17] мәкаләсе басылып чыкканнан соң, Г. Тукай һәм М. Гафуриларның татар әдәбиятында тоткан урыннары, шигъриятләренең аерым сыйфатлары тирәсендә бәхәс куерып китә. Бу мәкаләгә җавап төсендә «Волжский листок» газетасында Касыйм Уралец тәхәллүсе белән «Татарские поэты» язмасы дөнья күрә [18]. К. Уралец М. Гафуриның Россиядә һәм Себердә танылганлыгын һәм популярлыгын нәкъ менә аның фән һәм техниканың кеше тормышына алып килгән яңалыгын, белем-гыйлемнең кыйммәтен сәнгатьчә күрсәткән «Себер тимер юлы, яки Әхвале милләт» (1904), «Электрик фонарена хитап» (1907) кебек әсәрләренә нигезләнеп дәлилли: «Әмма Гафури? Бу –

бөтен Русия һәм Себердә мәшһүр. Гафури татарларга укырга куша. Аларның наданлыклары өчен кайгыра» (сүзгә-сүз тәрҗ.. – *Т. Г.*) [18]. К. Уралец карашынча, М. Гафури, шөбһәсез, яңа татар әдәбиятының бизәге. Язма авторы аны Америка шагыйре Уитмен Уолт (1819–1892) белән янәшә куя. Ф. Әмирхан «Татар шагыйрьләре» (1908) мәкаләсе белән язмаларда күзәтелгән аерым бәхәсле урыннарга мөнәсәбәт белдереп йомгак ясый [19, 60–63 б.]

XX гасыр башы сүз сәнгатендә, публицистикасында һәм әдәби тәнкыйтендә актуаль булган татар җәмгыятендә хатын-кызларга мөнәсәбәтне уңай якка үзгәртү, аларга белем, ирек һәм азатлык бирү проблемасы романда да кузгатыла һәм ул татар милләте алгарышының бер юлы буларак карала: «...һәр милләтнең мәртәбә галиясе (югары дәрәҗәсе. – *Т. Г.*) хатыннарының тәрбиясе вә тәрәккыйләре мәртәбәсенә мөсави (тигез. – *Т. Г.*) була. Хатыннар – милләт аналары. Ана ничек кылса, бала шулай була. Безнең милләтнең артта калуы фәкать, фәкать хатыннарымызны дүрт стена эченә ябып, хиҗаб (пәрдә. – *Т. Г.*) астында черетүемездәндер. Безне хиҗаб, безне шул артта калдырды. Һәр милләтнең тәрәккый итүе хатыннары аркасындадыр» [5, 155 б.]. Бу фикер икенче нотыкчы тарафыннан үстерелеп, бала тәрбиясенә, аңа дөрес тәрбия бирү һәм шул юл аша рухи юлбашчылар, милли лидерлар җитештерү проблемасына бәйләп куела: «...һәр милләтнең тәрәккый вә тәгали итмәге (милләтнең үсеше һәм бөеклеккә ирешүе. – *Т. Г.*) – балаларның гүзәл тәрбия кылынуына баглыдыр. Бүгенге балалар киләчәк көндә милләтнең аталары, юлбашчылары, көтүчеләре булачак. Көтүче кая кауласа, көтү шунда барачагы мәгълүм» [5, 155–156 б.]. Тирән иҗтимагый-фәлсәфи мәгънәгә ия булган «көтүчеләр» сүзенең кулланылу традициясе, борынгы шәрыктан башланып, XX гасыр башына барып тоташа. «Күчерелмә мәгънәдә исә ул дөньяның акыл ияләре булган пәйгамбәрләр, галимнәр, философлар, рәссамнар һәм язучыларны атый» [20, 229 б.], – дип шәрехли әдәбият галиме Р. Ганиева.

Алда ассызыкланган хөкемнәр, бер яктан, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан. Г. Тукай, С. Рәмиев әдәби әсәрләрендә, икенче яктан, тәнкыйди-гыйльми, публицистик хезмәтләрдә тәкрарланган идеяләр белән бик тә аваздаш. Мәсәлән Г. Исхакыйга мөрәҗәгать итик. Ул үзенең программ әсәре «Ике йөздән соң инкыйраз» (1902–1904) хыялый-публицистик повестенда болай дип яза: «Һәр милләтнең яртысы хатыннар, һәр милләтнең рухын саклаучылар – хатыннар, һәр милләтнең теленең хосусый тәләффызларын (әйтелешләрен. – *Т. Г.*) шивәсен саклаучылар – хатыннар. Киләчәктәге ата булачак ирләрне, ана булачак кызларны тәрбия кылучылар – хатыннар идеке һәркемгә мәгълүм бер мәсьәлә булгач, минемчә, аларны тәрбия кылырга кирәкме йә юкмы? мәсьәләсе һәркемгә җавап бирерлек бер нәрсәдер» [11, 180 б.]. Милләт язмышында, тарихи барышта рухи юлбашчылар, остазлар, милләт хадимнәре, тарихи шәхесләр, «көтүчеләр»нең роле турындагы публицистик-фәлсәфи уйланулар Җ. Вәлидинең «Татар әдәбиятының барышы» (1912) [22], Н. Гасрыйның «Мәдрәсә мәсьәләсе (съезд дикъкатенә)» (1914) [23], Ф. Әмирхан-ның «Безнең хыялларда Мәрҗани күләгәсе» [24] һәм башка язмаларда чагыла. Аерым алганда, татар дөньясындагы уяну хәрәкәтен уңаеннан Җ. Вәлиди аерым шәхесләрнең татар халкы язмышында, тарихи барыштагы урыны хакында уйлана һәм милли үсешне, рухи яңарышны аларның эшчәнлеге нәтиҗәсе итеп тә карый [22, 119 б.].

Җыелышта чыгыш ясаучылар үз фикерләренең дөреслеген гарәп, төрек әдәбиятларыннан мисаллар китереп раслыйлар. Татар хатын-кызлары хокукына нисбәтле Мисырның мәшһүр галиме, хокук белгече, фәлсәфәче, гарәп язучысы, мөселман хатын-кызлары азатлыгы көрәшчесе Касыйм Әминнең (1865–1908) «Тәхрирел-мәръат» («Күзге яктысы») әсәре телгә алына. Бу китапны татарчага илаһият галиме, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Закир Кадыйри (1878–1954) тәрҗемә итә. Ф. Әмирхан әсәрнең темасына уңай мөнәсәбәт белдереп, тәнкыйть мәкаләсе белән чыгыш ясый. Тәнкыйтьче мәкаләсендә Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романындагы хатын-кызның азатлыгы, белемле, тигез хокуклы ананың бала тәрбиясендәге урыны хакындагы фикерләр бөтен төгәллеге белән кабатлана. «„Тәхрирел-мәръат“ („Көзге яктысы“. – *Т. Г.*) һәм „Әлмирател-җәдидә“ („Хатын-кыз азатлыгы“. – *Т. Г.)* бу ике китап ислам галәмендә тәэлиф ителгән, хөррияте нисага даир (хатын-кыз азатлыгына бәйләнешле. – *Т. Г.*) иң әүвәлге һәм иң мөкәммәл китаплардан хисап ителергә тиешледер» [25, 98 б.]. Бу әсәргә шулай ук тарихчы, филолог, журналист Г. Батталның да (1880–1969) тәнкыйть мәкаләсе язу мәгълүм

[26]. Мөселман җәмгыятендә хатын кыз проблемасы илаһият галиме, публицист, җәмәгать эшлеклесе М. Бигиев (1873–1949) эшчәнлегендә төп темаларның берсе булып тора. Галим үзенең күп кенә хезмәтләрендә хатын-кыз мәсьәләсен тирәнтен тикшерә. Җәмгыятьтә хатын-кызларның тулы хокуклыгын танырга, мөселман дөньясында аларның дәрәҗәсен күтәререгә чакыра. Аның бу юнәлештәге эзләнүләре күпсанлы мәкаләләрендә һәм 1916 елда тәмамланып, бары тик 1933 елда Берлинда басылып чыккан «Коръән Кәрим аять кәлимәләре хозурында хатын» китабында чагылыш таба [27, 30–31 б.].

Бала тәрбиясе һәм бу процестта белемле, тәрбияле, тирән мәгълүматлы ананың роле татар галәмендә бик хөрмәт ителгән, татар тормышын европалаштыруга турыдан-туры катнашы булган төрек язучысы, мәгърифәтчесе, журналисты, тәрҗемәчесе, абруйлы Әхмәд Мидхәтнең (1844-1913) «Чужык» («Бала»), «Ана», «Пәдәр улмак сәнгате» («Ата булу сәнгате») дини, тәрбияви-педагогик хезмәтләре белән нигезләнә [5, 156 б.]. Төрек мәдәниятен яңартуга һәм аны үстерүгә керткән эшчәнлеге зур ихтирам белән бәяләнгән Ә. Мидхәт исеме романда берничә тапкыр очрый. Г. Ибраһимов үзенең гыйльми, тәнкыйди хезмәтләрендә, хатларында татар әдәбияты һәм мәдәнияте үсеше закончалыкларына, әдәби-мәдәни бәйләнешләр, төрек сүз сәнгате хосусиятләре проблемаларына нисбәтле, Ә. Мидхәт шәхесен, аның киңкырлы эшчәнлеген һәрдаим күз уңында тота: «Әхмәд Мидхәт әфәнде, иң әүвәл, бер төрек әдибе, төрек журналисты, төрек галиме, кулыннан килгән кадәр ислам диненең фәлсәфәсен тикшергән зат; икенчедән, әсәрләре белән Кара диңгезнең бу ягындагы төрек – татарларга, госманлы төрек әдипләре арасында иң якын торган бер хөрмәтле карт иде» [28, 220 б.] – дип яза Г. Ибраһимов «Әхмәд Мидхәт әфәнде (Ризаэтдин бине Фәхретдин әсәре)» дигән рецензиясендә. Тәнкыйтьче бу могтәбәр шәхес эшчәнлегенең кыйммәтен, төрки-тугандаш халыкларга иткән файдасын төрек-татар әдәби һәм мәдәни контекстенда югары бәяли: «Әхмәд Мидхәт әфәнденең төрек-татар галәменең „бөек“ләреннән булуында һич шөбһә юк. Төркия бундый адәмнәрне бик сирәк җитештерә. Хәтта госманлы әдәбиятында андый „халыкчы“ каләм чыкканы юк әле» [28, 230 б.]

Шәкертләр чыгышларында XX гасыр башы татар прозасында аеруча, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан әсәрләрендә, драма әсәрләрендә кызыл җеп булып сузылган иске карашлы, надан, әхлаксыз, милләткә хезмәткә аркасы белән торган руханиларга, ишаннарга каршы көрәш мәдрәсәләрне ислах итүнең төп шартларыннан берсе төсендә әйтелә. «Безнең көннәр» романындагы тарихи, иҗтимагый дәлилләргә бай кызу нотыклары белән танылган Сөләйман Сәйфуллинның кискен карашлары Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәренең кереш өлешендә күрсәтелгән татар милләтен инкыйразга китергән сәбәпләргә турыдан-туры барып тоташа: «Безне кем бетерде дисез? Безне муллалар бетерде... Бездә муллалар наданнар, җаһилләр, гыйлемсез вә фикерсезләр... Болар – милләт микроблары... Болар – безне гасырлар буенча ашап, әүвәлге шәүкәтемезне бетергән, безне аяктан еккан зарарлы кортлардыр. Без милләт өчен тырышсак, без милләтемез тәрәккый итсен дисәк, тәрәккый вә мәдәният юлына аркылы кискә булып яткан ишаннар вә мөтәгассыйб муллалар белән көрәш башларга, аларны бара торган юлымыздан читкә алып ташларга тиешлемез» [5, 157 б.]. Шәкертләр кузгалышы үзенең иң югары ноктасына җитеп, мәдрәсә эчендә башланган тәртипсезлекләр вакытында «Мәдрәсәи Исламия» җитәкчесенең һәм хәлфә-мөдәррисләренең халәте Дәрдемәнд, Н. Думави, Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Бабич шигъриятләрендә, Г. Коләхмәтов нәсер-хикәяләрендә, шулай ук Г. Ибраһимов үзе дә бик яратып кулланган күчерелмә, фәлсәфи мәгънәдәге кораб, көймә образы аша көчәйтелә: «Менә-менә батып һәлак булып барган корабның командиры ни-нәрсә хис итсә, мөдәррис һәм мөгаллимнәр шул халәткә килделәр» [5, 102 б.].

Романда шактый зур идея-эстетик вазифа йөкләнгән Нигъмәт казый һәм җентекләп сурәтләнгән Давыт Урманов чыгышларында Ислам дине һәм мәдәният, дин һәм милләт, дин һәм заман мөнәсәбәтләре проблемаларына зур урын бирелгән. Алар Исламның бөтен тәгълиматы һәм рухының мәдәният белән бергә баруын исбатлый. Гыйлемгә, тырышлыкка Коръән Кәримдә югары бәя бирелү әйтелә: «Исламның нигезе булган Коръән Кәримнең иң беренче иңгән аятенең иң беренче сүзе „Икъраэ“ кәлимәи таибәседер (яхшы сүзедер. – *Т. Г.*). „Икъраэ“, димәк, „укы, бел, гыйлем ал“, димәктер. Башка һичбер дәлил булмаса, ялгыз шушы бер сүз дә Исламның мәдәниятка, гыйлемгә дәгъва итүче, аларга хезмәт итүче бер

дин икәнен исбатка җитәр иде» [5, 159 б.]. Бу фикерләр, бер яктан, Г. Ибраһимовның үз әдәби әсәрләренә, мәкаләләренә һәм, икенче яктан, Ф. Әмирхан, Н. Гасрый публицистик язмаларына, өченчедән, Җ. Вәлидинең фәнни хезмәтләренә барып тоташа. Мөселманнар Ислам рухын аңлап, шуның белән эш иткән чорда мәдәният һәм хакимият баскычының иң югары баскычына менүләре раслана. Җ. Вәлиди бу мәсьәләгә үзенең татар әдәбиятын өйрәнүнең методологик проблемаларына багышланган хезмәтләрендә зур урын бирә. Әдәбият галиме һәм профессиональ тәнкыйтьче башта милләтнең дине белән гыйлеме һәм мәдәнияте бер мәгънәдә йөрүен әйтә (сүзгә-сүз тәрж. – *Т. Г.*) [29, с. 206 ]. Җ. Вәлиди динне «мәдәнияткә бер әсас (нигез. – *Т. Г.*)», «мәдәнияткә менү өчен өчен бер баскыч» дип карый [22, 351 б.].

Ислам дине кануннары сагында торучылар һәм шулай ук Давыт Урманов та үзенең фикри үсешенең икенче баскычында «Ислам милләтен аякка бастыру, аны яңадан тәрәккый вә мәдәниятле ясау өчен, шул мәңгелек нур булган Исламны каплаучы яһүд мәҗүсият болытларын таратып, саф вә хакыйкый Исламга кайтару» [5, 164 б.] фикерен алга сөрә. Алар Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» (1913) хезмәтендә, Ф. Әмирхан публицистикасындагы карашларга аваздаш.

Аерым чыгышларда мәгърифәтчелек, уку-гыйлем, тәрбия проблемаларыннан тыш социаль: ярлыллык, җирсезлек, сәяси изелү мәсьәләләре дә күтәрелә һәм алар татар милләтенең икътисади үсешен тоткарлаган сәбәпләр буларак ассызыклана [5, 156 б.]. Иҗтимагый гаделлек, милли, социаль азатлык, тигезлек, шәхес иреге өчен көрәш темасы эсер, татар халкының социаль һәм милли азатлык юлбашчысы, Г. Исхакыйның 1906–1910 еллар публицистик эшчәнлегенең кыйбласын билгели. «Безнең мәсләкемез һәм миллият» (1906), «Хөкүмәт һәм халык» (1906), «Җирне халыкка бирү мәсьәләсендә думада өч партия» (1906) һәм башка язмалары бу яктан игътибарга лаек [30].

«Безнең көннәр» романында тирәлек, тарихи вакыйгалар, замана йогынтысында геройлардагы идеаллар үзгәрешен, фикри үсеш баскычларын сурәтләүгә зур урын бирелә. Нотыкчылар, шул исәптән Давыт Урманов та, милли чынбарлыкны асылыннан үзгәртеп кору проблемасына нисбәтле, үзләре кичергән фикри үсеш баскычлары хакында сөйли. Төп каһармандагы үзгәреш язучының «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендәге Зәки шәкертнең, «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә»дәге (1909) Сәлимнең, «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914) әсәрендәге хикәяләүче «мин»нең фикри үсеш баскычлары белән туры килеп кенә калмый, ә үсә-үзгәрә барып, тәмамланган төс ала: «беренче баскыч – кадимче, икенче баскыч – дин ислах итүче, өченче баскыч – татар милләтчесе, дүртенчесе – инсаниятчелек, бишенчесе – социалистлык». Романдагы аерым күренешләрнең, геройлар эш-гамәлләренең әдипнең башка әсәрләре белән бәйләнеше мәсьәләсе галимнәр тарафыннан да билгеләнгән. Татар әдәбиятында әдәби типларның үзенчәлекләре, структурасы анализланган «Әдәби типлар механизмы» (1929) китабы авторы Х. Вәли үзенең «Зәки шәкертнең...» басылып чыгуына һәм язучы әдәби эшчәнлегенә 20 ел тулу уңаеннан язылган юбилей мәкаләсендә: «Зәки безнең татар матур әдәбиятында ислахчы шәкертнең чын-чын тибы ул! Әдип Зәкидә ислахчы шәкертнең бөтен эчке мөндәриҗәсен биргән» [31, 54 б.] – дип ассызыкласа, Г. Нигъмәти «Яшь йөрәкләр» психологик романы белән эчке бәйләнешне күрсәтә [11, 117 б.].

Шул ук вакытта Г. Ибраһимов героеның эш-гамәлләре, рухи тартышлары, фикри инкыйлабы Г. Исхакыйның «Мөгаллим» (1908) пьесасындагы Салих, «Тартышу» (1907, 1917) тарихи-инкыйлаби драмасындагы инкыйлабчылар: Закир, Сабир, Насыйр, Шәйхетдин; Ф. Әмирханның «Яшьләр» (1909) драмасындагы Йосыф, Газиз; Г. Коләхмәтовның «Ике фикер» (1906), «Яшь гомер» (1908) әсәрләрендәге Давыт, Гали һәм башкаларныкы белән бик тә аваздаш. Язучы релистларча эш итеп, татар яшьләрендәге үзгәрешләрне гомумиләштереп бер типта – Давыт Урмановта сәнгатьчә гәүдәләндерүгә ирешә. Г. Нигъмәти романның беренче вариантын бәяләгән рецензиясендә болай дип яза: «Ул татар эсерларының уртак характер сыйфатларын бергә җыючы сурәт, әсәрдә аның үсеш, үзгәреше һәм әдип тарафыннан аңа бирелгән бәя шул вакыттагы бөтен татар эсерларына, шулар хәрәкәтенең үсешенә бирелгән бәя дип каралырга тиеш» [11, 104 б.]. «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (1909) хикәясенә рецензия язган Н. Гасрый [**32**], Җ. Вәлиди [33] 1910 елларда ук «Г. Ибраһимовның Сәлим образында инкыйлаб һәм реакция елларында зыялы татар яшьләрендәге фикри үзгәрешләрне сурәтләвен, әсәр идея

эчтәлегенең заман әдәбияты белән бәйләнешен билгелиләр» (сүзгә-сүз тәрж. – *Т. Г.* ) [34, с. 154–155].

Күңеле белән халык һәм хөррият юлында йөрүче яшьләргә тартылган Кадыйр бай малае Йосыфҗанның матди ярдәме белән аякка басып китеп, хәзер югары рәсем мәктәбендә белем алган студент-рәссам, музыкага сәләтле Камил Ходаяров образы Г. Ибраһимовның әдәбиятка, рәсем һәм музыка сәнгатьләренә карашын гәүдәләндерүгә хезмәт итә. Бу урында шуны да искәртеп китү урынлы булыр: романда патша хөкүмәте тарафыннан финанс-акча белән матди яктан тәэмин ителүдән мәхрүм булган татар уку йортларының берсе – «Мәдрәсәи Исламия»не дә Кадыйр байның үз хисабына тотуы искәртелә. Тырыш, югары әхлаклы, рәхмәтле, ачык фикерле К. Ходаяров «Безнең көннәр» әсәрен, бер яктан, язучының, әдәбият-сәнгатьнең халык, милләт һәм кеше тормышындагы урыны турында бәя-хөкемнәрен гәүдәләндергән «Көтүчеләр» хикәсендәге Вахит, «Яшь йөрәкләр» (1913) романындагы Зыя, «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914) әсәрендәге хикәяләүче образлары, аларның идеаллары белән бәйли. Икенче яктан, ул язучының «Татар шагыйрьләре» (1913), «Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз» (1915) һәм башка гыйльми, тәнкыйди хезмәтләрендәге сәнгатьнең генә бер милләтнең эчке рухын, психологиясен, табигатен ачу көче турындагы фикерләрен раслауга хезмәт итә. Яшь рәссамның сөю-сөелүдә бәхет идеясен буяулар ярдәмендә ачкан «Сөю», Давытны татар халкының дәүләтчелеген югалту һәм аның фаҗигасе турында тетрәнүле уйлануларга этәргән «Актык өмид» картиналары шул хакта сөйли [5, 330 б.]. Романдагы К. Ходаяров, шулай ук гимназист Таңгатаров, приказчиклыкны ташлап артист һөнәрен үзләштерә башлаган Габдрахман Ф. Әмирхан-ның «Тигезсезләр» (1914) психологик драмасындагы, дөньяви белем алып, татар милләтенең икътисади, иҗтимагый, мәдәни үсешенә хезмәт итүне кыйбла иткән Гомәр, Галиев, Рөкыяләр яңа буынының вәкилләре дә булып тора.

Социалист-революционер Давыт Урманов романда мәдрәсә чуалышларын, татар революцион яшьләрнең бишенче еллардагы көрәшләрен һәм реакция чорында тормышларын бәйләп торучы үзәк каһарман булып тора. Уртак максатлар һәм идеяләр белән бер-берсенә бәйләнмәгән вакыйгалар да Давыт Урманов шәхесе аркылы бер җепкә тагылалар. «Әсәрдә революцион яшьләрнең идеологы итеп бирелгән һәммә яшь аңа сүзсез хөрмәт белән олылап карый торган итеп күрсәтелгән Давыт менә шул» [11, 104 б.]. Безнең карашыбызча, Давыт Урмановның прототибы – ул вакытта эсерлар партиясенең актив сәясәтчесе булган Г. Ибраһимов. Татар милләтенең матди хәлен ныгыту, икътисади хәлен яхшырту, татар мәгарифен үстерү, татар халкын мәдәни яктан алга киткән башка милләтләр дәрәҗәсенә җиткерү максатын күз уңында тоткан милли идеологлар: Шиһабетдин Мәрҗани, Исмәгыйль Гаспралы, Рәшит Ибраһимов, Галимҗан Баруди, Риза Фәхретдинов, Муса Бигиев, Йосыф Акчура, Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов һәм башкалар арасында татарчылык хәрәкәтен нигезләүче Галимҗан Ибраһимов та бар.

«Безнең көннәр» романының бай образлар системасында XIX ахырында – XX гасыр башында татар җәмгыятен үстерүгә һәм яңартуга зур өлеш керткән күренекле шәхесләр, рухи юлбашчылар сәнгати гәүдәләнеш тапкан. Әсәрнең бу хасияте Г. Нигъмәти тарафыннан да ассызыклана һәм ул болай дип яза: «Әдип бишенче елгы татарлар арасында булган күренешләрне җитәрлек гомумиләштерү, типиклаштыру ясамыйча бирү юлын алган. Мәсәлән, аның „Мәдрәсәи Исламия“ хәрәкәтендә Уфаның „Мәдрәсәи Галия“се, каһарманнарның күп кенәсендә дә тарихи күрелгән шәхесләр натуралык дәрәҗәсендә точлык[2] сакланып бирелгәннәр (мәсәлән, Гали Мөдәррис, Кәрим Гайфи һ.б.лар. – *Г. Н.* )» [11, 116 б.]. Романның язучы тормышы һәм сәяси-иҗтимагый эшчәнлеге, шул чор татар тормышы, аерым тарихи шәхесләре белән бәйләнешенә П. Фалев та игътибар иткән: «Роман автобиографик мәгънәгә ия. Геройларның берсенә автор үзе чыгарылган. Башка хәрәкәт итүче кешеләргә дә билгеле тарихи шәхесләр туры килә. Романның әдәби образлары белән чынбарлык бәйләнешен ачу (әдәби-эстетик традицияләрне һәм яңа әдәби күренешләрне тикшерү белән бергә. – *П. Ф.*) безнең авторның иҗатына характеристика бирү өчен кирәк. Шул ук вакытта бу эш татар зыялылары тарихына материал да бирер иде»

[2] Точлык – рус телендәге «точный» сүзенең татар теленең гади сөйләмендә кулланылган формасы. Бу очракта төгәл, дөрес дигән мәгънәдә файдаланылган.

(сүзгә-сүз тәрж. – *Т. Г.*) [9, 375 б.]. Романда татар мәдәнияте тарихында тирән эз калдырган шәхесләрдән энциклопедик галим, мәгърифәтче, язучы Каюм Насыйри (1825–1902), язучы Әхмәт Уразаев-Кормаши (1855–1883), татар әдәбиятының классик язучысы, драматург Галиәсгар Камал (1879–1933); мәгърифәтче, мөгаллим, журналист Исмәгыйль Гаспралы (1851–1914), тарихчы, язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе Йосыф Акчура (1876–1935); җәдитче һәм җәмәгать эшлеклесе Габдерәшит Ибраһимов (1857–1944), язучы, мәгърифәтче, галим, дин эшлеклесе Ризаэтдин Фәхретдин (1859–1936), бөтен төрки-мөселман дөньясында зур абруй казанган мәгърифәтче, педагог, дин галиме Габдулла Бубый (1871–1922), азәрбайҗан җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, хокук фәннәре белгече Галимәрдан Тупчибашев (1862–1934) һәм башкалар бар һәм алар әсәрдә билгеле бер идея-эстетик вазифа башкара.

Әдәби әсәрдә «Мәдрәсәи Исламия» уку йортының мөдәррисе Кәрим Гайфигә зур урын бирелә, бу геройга әдип тарафыннан гаять әһәмиятле идея-эстетик вазифа йөкләнгән. Безнең карашыбызча, мәдрәсә мөдәррисе Кәрим Гайфинең прототибы булып, гәрчә исеме һәм фамилиясе әсәрдә үзгәртелмичә берничә тапкыр телгә алынса да, әдип, журналист, иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер иясе Фатих Кәрими (1870–1937) тора. Романның XXXI бүлегендә Кәрим Гайфи турында шактый җентекле бирелгән сыйфатламадагы аерым фактлар, холык сыйфатлары Ф. Кәриминекенә туры килә. Тарихчы һәм әдәбият галиме М. Госманов шәхесләребез сериясендә Ф. Кәримигә багышлап чыгарылган фәнни-биографик җыентыкка язган «Затлылык үрнәге» кереш сүзендә бу зат эшчәнлегенең һәм шәхесенең кыйммәтен төрки-мөселман мәдәнияте контекстында бәяли: «...Фатыйх әфәнде Кәриминең бер татар дөньясында гына түгел, бәлки Русиядәге барлык төрки-мөселман халыклары масштабында иң абруйлы, күпләргә үрнәк аксакал мөхәррирләрдән исәпләнүе табигый иде» [35, 11 б.].

Әсәрдә Кәрим Гайфи тирән белемле, тырыш, булдыклы, җитди, үз эшенә ихласи күңелдән бирелгән зат буларак тәкъдим ителә. Г. Ибраһимов аны яратып, симпатия белән тасвирлый: «Кечерәк буйлы, нәзек гәүдәле, кызыл-саргылт йөзле, гасаби табигатле, ләкин якты күзләре җитди фикер, җитди игътикад төсе белән ялтырап торган бу зат чын мәгънәсе белән фән кешесе иде. <...> Төркиядә калса, фән галәмендә яхшы урын тотачагына шөбһә итмиләр, теләсә, дәүләт хисабыннан Ауропага да йибәреләчәк, кайтып, Төркиядә профессор булачак иде» [5, 105 б.]. Шушы сыйфатлары аркасында гыйльми-педагогик даирә, шәкертләр тарафыннан да ихтирамга лаек шәхес төсендә бәяләнә. Беренче дәресләреннән үк тирән белемле, ялкынлы нотыклары белән сихерләп, Кәрим Гайфи шәкертләрнең иң яраткан мөдәррисләренә әверелә.

Алга таба Г. Ибраһимов, Төркиядә белем алганда, күп мәсьәләләрдә ярдәм иткән остазы Әхмәд Мидхәт әфәнденең киңәше белән Кәрим Гайфинең Россиягә кайтуы турында яза. Төрек галиме Х. Барган Т. Гыйлаҗев белән бергәлектә язылган мәкаләсендә, Ф. Кәриминең Төркиядә уку йортын тәмамлаганнан соң, үз иленә кайтып, татар милләтенә хезмәт итү шарты белән төрек әдәбияты һәм мәдәниятенең яңарыш юлы башында торган Әхмәд Мидхәт әфәндедән фатиха алуын хәбәр итә. «Әхмәт Мидхәтнең Идел-Урал буе төрки халыклары арасында иң якын бәйләнештә торган һәм „рухи угълым“ дип атаган кешесе Фатих Кәрими була. Ф. Кәрими, моңа кадәр китаплары аша гына белгән Әхмәт Мидхәт белән 1892 елда Истанбулга килгәч, шәхсән таныша һәм алга таба аның иң якын рухи дәвамчысына әверелә. Ф. Кәрими, кайсы мәктәптә уку яхшырак булуы турында фикерен белер өчен, Ә. Мидхәт янына бара. Ә. Мидхәт аңа: „Укуыгызны бетергәч, сез биредә калу фикерендәме? Яисә ниятегез, илегезгә кире кайтып, милләттәшләрегезгә хезмәт итүме? Әгәр биредә калу фикерендә булсагыз, миннән сезгә бернинди киңәш тә юк, үзегез хәл итегез. Әгәр инде илегезгә кире кайту уенда булсагыз, бу минуттан минем рухи угълым буласың, һәр төрле киңәшкә һәм ярдәмгә әзермен“ [36, 98 б.], – дип әйтә. Әхмәт Мидхәт шул көннән алып, „рухи улы“ Ф. Кәрими 1896 елда укуын тәмамлаганга кадәр һәрдаим ярдәм итеп тора» [37, 76 б.]. Алда әйтелгәнчә, Г. Ибраһимов тәнкыйди язмаларында, хатларында, нәфис әдәбият әсәрләрендә төрек мәдәнияте, сүз сәнгате, иҗтимагый-фәлсәфи фикере тарихында Ә. Мидхәтнең урынын, иҗат эшеленең киң тармаклы эшчәнлеген уңай бәяли. Төрек әдәбиятының классик әдибе, төрек мәдәнияте яңарышының олы юлбашчысы мөнбәренә күтәрә.

### Натиҗәләр

1. Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» (1920) романында тышкы һәм эчке бәйләнешләрнең күптөрле формалары күзәтелә. Язучы XX гасыр башы татар язучылары, фикер ияләре, дин галимнәре хакында мәгълүматлар бирә, хәбәрләр урнаштыра, шулай ук теге яки бу мәдәният үсешен тәэмин иткән шәхесләр хакында җентекле тасвирлама урнаштыра. Романның структурасында чагылган эчке бәйләнешләр әдәби һәм иҗтимагый-тарихи шартларга нисбәтле, иң беренче чиратта, проблематик-тематик дәрәҗәдә ачыклана.

2. Г. Ибраһимов әсәрендә XX йөз әдәби-тарихи чорының алдынгы иҗтимагый-әхлакый карашлары, милли мәгариф, дөньяви фәннәр, милләт, дин, ватан, әдәбият, сәнгатькә мөнәсәбәтле фикерләр гәүдәләнә. Романда татар тормышын яңартып кору һәм мәдәниләштерү юллары хакында язучының үз карашлары белән берлектә XX гасыр милли сүз сәнгатенең күренекле әдипләре Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, С. Рәмиев, Г. Камал, М. Гафури һәм башкаларның фикерләре һәм уйланулары тупланган. Шулай ук алар күренекле фикер ияләре, фәлсәфәчеләр, илаһият галимнәре, мәгърифәтчеләр, галимнәр И. Гаспралы, М. Бигиев, Р. Ибраһимов, Р. Фәхретдинов, Җ. Вәлиди, Н. Гасрый һәм башкаларның эшчәнлегендә кызыл җеп булып сузыла.

3. «Безнең көннәр» романының беренче вариантында сурәтләнгән татар тормышының картинасы, катлаулы геройлар язмышы, кадимчелек һәм җәдитчелек көрәшләре, милләтчелек, халыкчылык карашлары ярдәмендә милләт тормышын үзгәртүнең эволюцион юлы, ягъни татар мәдәниятен, әдәбият-сәнгатен үстерү, милли мәгарифенә реформа ясау, милли үзаң формалаштыру, матди хәлен ныгыту аша татар җәмгыятен яңарту юлы күрсәтелә. Татар зыялыларының террор, кан түгү, революциядән ерак торуы турындагы фикер объектив рәвештә үсеп чыга.

### Йомгак

Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» әсәре (1920) бик хаклы рәвештә татар җәмгыятен тамырдан үзгәртеп кору турындагы иҗтимагый-сәяси, милли, фәлсәфи, этик-әхлакый, дини карашлар бергә килеп тоташкан иҗтимагый-тарихи роман булып тора. Язучы әдәби әсәрдә сурәтләнгән тарихи-инкыйлаби вакыйгалар һәм аларда катнашкан төрле социаль катлам вәкилләренең идеаллары, язмышлары, дөньяга карашлары, иҗтимагый позицияләре аша татар милләтен саклап калу, аны үстерү һәм мәдәниләштерү юлларын ачыклый һәм аларны татар җәмәгатьчелегенә күрсәтә, үзен киң һәм тирән карашлы шәхес итеп таныта.

**Әдәбият**

1. Галимҗан Ибраһимов: хатлар һәм документлар / Төзүче Ф. Ибраһимова. Казан, 2000. 464 б.

2. *Ибраһимов Г.* Язучыдан (Икенче басмага сүз ахыры урынында) // Әсәрләр. Сигез томда: 4 т.: Безнең көннәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. Б. 435–440.

3. *Ибраһимов Г.* Сайланма әсәрләр. 3 һәм 4 китап. «Безнең көннәр». Казан: Таттосиздат, 1934. 488 б.

4. *Ибраһимов Г.* Әсәрләр. Сигез томда: 4 т.: Безнең көннәр / төз. иск. һәм аңл. әзерл. А. Ш. Шамов; текстл. әзерл. А. Ш. Шамов, Р. Р. Гайнанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 462 б.

5. *Ибраһимов Г. Г.* Әсәрләр: 15 томда. 4 т.: роман / төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл. Г. Г. Батыршина. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 376 б.

6. *Сәйфи-Казанлы Ф.* Галимҗан Ибраһимовның соңгы әдәби әсәрләреннән «Безнең көннәр» романы (Кызыл шәрык. 1920. № 3–4. 142–145 б.) // Г. Г. Ибраһимов. Әсәрләр: 15 томда. 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. Б. 364–368.

7. *Атнагулов С.* Безнең көннәр (Эшче. 1920. 20 май) // Г. Г. Ибраһимов. Әсәрләр: 15 томда. 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. Б. 368–372.

8. *Губайдуллин Г.* Новые произведения Галимджана Ибрагимова (Вестник научного общества татароведения. 1925. № 1–2. С. 65–66) // Г. Г. Ибраһимов. Әсәрләр: 15 томда. 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. Б. 368.

9. *Фалев П.* Татарский революционный роман (Наука и просвещение. 1922. № 1. С. 19–21) // Г. Г. Ибраһимов. Әсәрләр: 15 томда. 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. Б. 373–375.

10. Габдрахман Сәгъди: фәнни-биографик җыентык / Төзүчеләр Д. Заһидуллина, Ч. Гыйлаҗева. Казан: Җыен. 2008. 416 б.

11. *Нигъмәти Г.* «Безнең көннәр» һәм аның стилендә бишенче еллар сыйнфый көрәшенең чагылышы // Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. Б. 92–118.

12. *Җәләлиева М. Ш.* «Безнең көннәр» романының ике варианты // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 75–85.

13. *Даутов Г. Ф., Әхмәдгалиева Г. Г.* Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романында татар милли мәгариф системасының бирелеше // Наследие

Галимджана Ибрагимова в контексте многообразия культур: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Ибрагимова. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 128–131.

14. *Рәмиев З. З.* Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең текстологиясе ни хәлдә? // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2007. Б. 81–86.

15. *Ибраһимов Г. Г.* Әсәрләр: 15 томда. 5 т.: роман / төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл. Ә. Х. Алиева. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 423 б.

16. *Гыйлаҗев Т. Ш.* Татар әдәбияты. XX гасыр башы: Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 239 б.

17. *Пинкевич А*. Очерки новейшей татарской литературы // Волжско-Камская речь. 1908. 21 мая.

18. *Уралец К.* О татарских поэтах // Волжский листок. 1908. № 34. 10 июня.

19. *Әмирхан Ф.* Татар шагыйрьләре // Ф. З. Әмирхан. Әсәрләр: 4 томда. 4 т.: Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 60–63.

20. *Ганиева Р.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во КГУ, 2002. 272 с.

21. *Исхакый Г.* Әсәрләр: Унбиш томда. 1 т.: Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908) / төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл. Л. Гайнанова; кереш мәкалә авт. М. Хәсәнов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 399 б.

22. Җамал Вәлиди: әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз. Диләрә Абдуллина, Җәүдәт Миңнуллин. Казан: Җыен, 2010. 624 б.

23. *Гасрый Н.* Мәдрәсә мәсьәләсе (съезд дикъкатенә) // Ил. 1914. 17 июнь (№ 31).

24. *Әмирхан Ф.* Безнең хыялларда Мәрҗани күләгәсе // Ф. З. Әмирхан. Әсәрләр: 4 томда. 4 т.: Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 132–137.

25. *Әмирхан Ф.* Яңа китаплар. «Тәхрирел-мәрьат» һәм «Әльмирател-җәдидә» тәрҗемәләре // Ф. З. Әмирхан. Әсәрләр: 4 томда. 4 т.: Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 98–100.

26. *Баттал Г.* Тәнкыйть. Сүз башы // Шура. 1909. № 12. Б. 360–362.

27. *Бигиев М.* Избранные труды: В 2 т. / сост. и пер. с осман. А. Хайрутдинов. Т. 2: Обращение к Великому Турекому Национальному Собранию, Введение к трактату «Аль-Муафакат», Воззвание к мусульманским нациям, Женщина в свете священных аятов благородного Корана. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. 256 с.

28. *Ибраһимов Г.* Әхмәд Мидхәт әфәнде (Ризаэтдин бине Фәхретдин әсәре) // Г. Г. Ибраһимов. Әсәрләр: 15 томда. 6 т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1914) / төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл. З. Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Д. Ф. Заһидуллина. Академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. Б. 220–230.

29. *Гилазов Т. Ш.* Вклад Джамала Валиди в историю литературной мысли у татар // Филология и культура. Philology and Culture. 2015. № 4 (42). С. 206–210.

30. *Исхаков М. Г.* Әсәрләр: 15 томда. 6 т.: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре (1902–1914). Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 447 б.

31. *Вәли Х.* «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» // Т. Ш. Гыйлаҗев. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 49–56.

32. *Гасрый Н.* Яшьләр хәятыннан бер ләүхә // Ил. 1914. 2 гыйнвар (№ 10).

33. *Вәлиди Җ.* Яшьләр хәятыннан бер ләүхә // Вакыт. 1914. 26 гыйнвар.

34. *Гилазов Т. Ш.* Рассказ Г. Ибрагимова «Один эпизод из жизни молодежи» в литературной критике 1910-х годов // Филология и культура. Philology and Culture. 2017. № 2 (48). С. 153–158.

35. *Госманов М.* Затлылык үрнәге // Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик очерк = Фатих Карими: Научно-биографический сборник. Казан: Рухият, 2000. 320 б.

36. *Kerimi F.* Ahmet Mithat Efendi ve Şimal Türkleri // Türk Yurdu, 1912, sayı 30, sh. 97. (төрек телендә).

37. *Барган Х., Гыйлаҗев Т. Ш.* Әхмәт Мидхәт әфәнде һәм Идел-урал төркиләре // TATARICA. 2014. № 1 (2). 70–80 б.

# РОМАН Г. ИБРАГИМОВА «БЕЗНЕҢ КӨННӘР» («НАШИ ДНИ») (1920) В СВЕТЕ ЛИТЕРАТУРНЫХ И КУЛЬТУРНЫХ ВЗАИМОСВЯЗЕЙ

**Тагир Шамсегалиевич Гилазов,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
tgilazov@bk.ru.

В статье анализируется роман известного татарского писателя и общественного деятеля Г. Ибрагимова «Безнең көннәр» («Наши дни») (1920). В этом произведении писатель сумел изобразить различные слои татарского общества в годы Первой русской революции. Роман,

относящийся к раннему творчеству писателя, отличается от других его произведений актуальностью поставленных в нем социальных, просветительских, национальных проблем. С одной стороны, это произведение оказалось созвучно по ряду освещаемых проблем с произведениями таких классиков современности, как Г. Исхаки, Г. Тукай, Ф. Амирхан, С. Рамиев, Г. Камал, Н. Думави. С другой стороны, наблюдается определеннное родство со взглядами Дж. Валиди, Н. Гасри, И. Гаспринского, М. Бигиева в постановке вопроса о необходимости обновления общества и культуры. В то же время в этом произведении отчетливо проявляются творческие связи Г. Ибрагимова с арабо-мусульманской, турецкой и западной культурами, философией, кораническими традициями. Цель исследования – изучить роман «Безнең көннәр» («Наши дни») в свете литературных, критических, общественных, нравственных, эстетических и философских взглядов начала XX века. В статье содержится краткая информация об истории бытования и изучения этого произведения.

**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, роман, литературные взаимосвязи, общественная мысль, культура